| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.09.2014 № 518

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2014 елның 29 октябрендә теркәлде, № 2462

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
25.07.2012 ел, № 592 боерыгы белән
расланган Билгеләнгән квота чикләрендә
инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек
һәм контрольлек буенча дәүләт функциясен
үтәү буенча Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

"Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек буенча, тикшерүләр үткәрү үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, дәүләт функциясенең федераль дәүләт стандартын раслау турында" 30.04.2013 ел, № 181-н Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы басылып чыгуга бәйле рәвештә, боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.07.2012 ел, № 592 боерыгы белән расланган Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламентына, яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) раслап, үзгәрешләр кертергә.

**Министр вазыйфаларын башкаручы** **А.Р.Хәсәнов**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25 сентябрь, 2014 ел, № 518 боерыгына кушымта

**Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек буенча, тикшерүләр үткәрү, үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек буенча, тикшерүләр үткәрү, үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш бәелән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының административ регламенты (алга таба – Административ регламент) билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек буенча (алга таба – күзәтчелек һәм контрольлек), тикшерүләр үткәрү, үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) административ процедуралары (гамәлләр) срокларын һәм эзлеклелеген билгели.

Дәүләт функциясе атамасы: тикшерүләр үткәрү, үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек итү.

1.2. Дәүләт функциясен Министрлык башкара

Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручы булып Министрлыкның халыкны эш белән тәэмин итүнең актив формаларын үстерү бүлеге һәм Министрлыкның юридик бүлеге (административ җаваплылыкка тарту турында беркетмәләр төзү ягыннан) (алга таба – Бүлекләр) тора.

Дәүләт функциясен үтәү Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры (алга таба – министр) Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) боерыгы белән тикшерү үткәрүгә вәкаләт бирелгән Министрлыкның дәүләти гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан хәл ителә.

1.3. Министрлык күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итүдә Татарстан Республикасы прокуратура органнары (алга таба – прокуратура органы) һәм Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү органнары (алга таба – халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре) белән хезмәттәшлек итә.

1.4. Дәүләт функциясен үтәүне җайга сала торган норматив-хокукый актлар исемлеге:

“Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында” 19 апрель, 1991 ел, № 1032-1 Россия Федерациясе законы (РСФСР һәм РСФСР Югары Советы халык депутатларының ведомостьләре, 1991, №18, 565 ст.); (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып) (№ 1032-1 Россия Федерациясе Законы);

“Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында” 24 ноябрь, 1995 ел, № 181-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст.; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып) (алга таба – № 181-ФЗ Федераль закон);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы, 30 декабрь, 2001 ел, № 195-ФЗ (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2002, № 1, (1 өлеше) 3 ст.; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Россия Федерациясенең гражданнары мөрәҗәгатьләрен карап тикшерү тәртибе турында” 2 май, 2006 ел, № 59-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст.; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып) (алга таба – № 59-ФЗ Федераль закон);

“Мәгълүматлаштыру, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүматны саклау турында” 27 июль, 2006 ел, № 149-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст.; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) һәм муниципаль күзәтчелекне хәл иткәндә юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” 26 декабрь, 2008 ел, № 294-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2008, № 52 (1 өлеше), 6249 ст.; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып) (алга таба – № 294-ФЗ Федераль закон);

“Электрон имза турында” 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., № 27, 3880 ст.; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып) (алга таба “Электрон имза турында” Федераль закон);

“Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) органнары һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм хосусый эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында” 30.06.2010, № 489 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 12.07.2010, № 3706 ст.; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып) (алга таба – № 489 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары);

“Федераль дәүләт медицина-социаль экспертиза учреждениеләре тарафыннан бирелә торган инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасы, инвалид баланы реабилитацияләүнең индивидуаль программасы формаларын раслау турында” 04.08.2008, № 379-н Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2008 елның 27 августында теркәлгән, № 12189, “Российская газета” 10.09.2008 ел, № 190) (алга таба – № 379-н РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы боерыгы);

“Дәүләт контрольлеген (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлекне хәл иткәндә юридик затларның, хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын саклау турында” Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында” 30.04. 2009, № 141 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2009 елның 13 маенда теркәлгән, № 13915, “Российская газета” 14.05.2009 ел, № 85) (алга таба – № 141 Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы);

“Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелек һәм контрольлек буенча, тикшерүләр үткәрү, үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән, дәүләт функциясенең федераль дәүләт стандартын раслау турында” 30.04.2013 ел, № 181-н Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (“Российская газета”, 2013, № 178);

“Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында” 12 май, 2003 ел, № 16-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (“Республика Татарстан”, 17.05.200 ел, № 99-100; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру турында” 19 июнь, 2006 ел, № 39-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (“Республика Татарстан”, № 127, 27.06.2006; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып);

“Инвалидларга һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарга эш урыннарын квоталау һәм резервлау турында” 24 июль, 2006 ел, № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы (“Республика Татарстан”, № 150, 28.07.2006; кертелгән үзгәрешләрдән чыгып); (алга таба – № 60-ТРЗ ТР Законы);

“Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 04.05.2007, № 170 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 16.05.2007, № 19, 0673 ст.) (алга таба – № 170 ТР МК карары);

“Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре” 15.08.2007 ел, № 388 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнарының норматив актлары җыентыгы, 05.09.2007, № 33, 1178 ст.; (кертелгән үзгәрешләрдән чыгып).

1.5. Күзәтчелек һәм контрольлек объектлары булып, оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына бәйсез рәвештә, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, хезмәткәрләренең исемлектәге уртача саны ким дигәндә 35 кешене тәшкил иткән һәм Россия Федерациясе законы һәм Татарстан Республикасы законы нигезендә үзләренә инвалидларны эшкә алу өчен квота билгеләнгән оешмалар (алга таба – оешмалар, эш бирүчеләр, юридик затлар) тора, устав (тупланма) капиталы

инвалидларның иҗтимагый берләшмәсе кертеменнән торган дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан, инвалидларның иҗтимагый берләшмәләреннән һәм алар тарафыннан оештырылган оешмалардан тыш, шулай ук үзләренә карата закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә юкка чыгару турында карар кабул ителгән оешмалардан тыш.

1.6. Күзәтчелек һәм контрольлек предметы булып оешмалар тарафыннан билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу өлкәсендә Россия Федерациясе законында һәм Татарстан Республикасы законында билгеләнгән таләпләрне үтәү тора.

1.7. Дәүләт функциясен үтәү билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу буенча тикшерүләрнең (алга таба – тикшерүләр) түбәндәге төрләрен үткәрү юлы белән хәл ителә:

планлы (күчмә, документар) тикшерүләр;

планнан тыш (күчмә, документар) тикшерүләр.

1.8. Вазыйфаи затларның күзәтчелек һәм контрольлекне хәл итүдәге хокуклары һәм бурычлары

1.8.1. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә хокуклы:

хезмәт таныклыгын һәм тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы күчермәсен күрсәтеп, тикшерү үткәрү максатында оешмада булуга;

тикшерү предметына керә торган мәсьәләләр буенча документлар һәм материаллар, шулай ук тикшерү предметына керә торган мәсьәләләр буенча оешма җитәкчесеннән яки аның вәкаләтле вәкиленнән (алга таба – оешма җитәкчесе) язмача аңлатмалар соратып алуга;

тикшерү предметына керә торган мәсьәләләр буенча оешма җитәкчесе һәм/яки хезмәткәрләре белән әңгәмәләр үткәрүгә;

тикшерелә торган оешма белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган экспертларны, эксперт оешмаларын планлы күчмә тикшерү үткәрүгә җәлеп итүгә.

1.8.2. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә бурычлы:

Россия Федерациясе законы нигезендә бирелгән мәҗбүри таләпләрне бозуларны кисәтү, ачыклау һәм аларга юл куймау вәкаләтләрен вакытында һәм тулы күләмендә үтәүгә;

Россия Федерациясе законын, тикшерелә торган оешманың законлы мәнфәгатьләрен үтәүгә;

билгеләнеше нигезендә, тикшерү үткәрү турында министр, министр урынбасары боерыгына туры китереп тикшерү үткәрүгә;

фәкать хезмәт бурычларын үтәү вакытында гына тикшерү үткәрүгә, хезмәт таныклыкларын, министрның, министр урынбасары боерыгы күчермәсен күрсәтеп кенә күчмә тикшерү үткәрүгә, ә планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү очрагында – тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү нигезендә документ күчермәсен күрсәтеп үткәрүгә;

тикшерү үткәргәндә оешма җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә комачауламауга һәм тикшерү предметына керә торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә;

тикшерү үткәрүдә катнашкан оешма җитәкчесенә, башка вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына керә торган мәгълүматлар һәм документлар тапшыруга;

оешма җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яки вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыруга;

ачыкланган бозу фактлары белән кабул ителә торган чараларны билгеләгәндә әлеге чараларның закон бозулар авырлыгына, аларның кешеләр тормышы, сәламәтлеге, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федеарциясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләр) өчен, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу өчен куркыныч белән янау ихтималын исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрнең, юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен нигезсез чикләүгә юл куймауга;

оешмалар тарафыннан үз гамәлләренә шикаять белдерелгәндә, үз гамәлләренең нигезлелеген Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә раслауга;

тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын үтәүгә;

оешмалардан Россия Федерациясе законында тапшыру күздә тотылмаган документлар һәм башка мәгълүматлар таләп итмәүгә;

күчмә тикшерү үткәрү алдыннан оешма җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкәләтле вәкиле үтенече белән аларны бу Административ регламент нигезләмәләре белән таныштыруга;

үткәрелгән тикшерү турында тикшерүләр учеты журналына язып куюга;

1.8.3. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләргә хокуклы була алмый:

таләпләр Министрлык вәкаләтләренә кермәгәндә, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләрнең һәм таләпләрнең үтәлешен тикшерүгә;

оешма җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле булмаган очракта планлы яки планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне хәл итүгә, № 284-ФЗ Федераль законның 10 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктындагы “б” пунктчасыннан тыш;

тикшерү объектлары булып тормаган яки тикшерү предметына кермәгән документлар, мәгълүмат тапшыруны таләп итүгә, шулай ук мондый документларның төп нөсхәләрен алуга;

тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган дәүләт сере, коммерция сере, хезмәт урынындагы сер, закон нигезендә сакланыла торган башка төрле сер булып торган мәгълүматны таратуга, Россия Федерациясе законында күздә тотылган очраклардан тыш;

тикшерү үткәрүнең билгеләнгән срокларын озайтуга;

оешмаларга үзләре хисабына контрольлек чаралары үткәрү турында контрольлек чаралары үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнәр бирүгә.

1.9. Үзләренә карата дәүләт күзәтчелеге һәм контрольлек чаралары хәл ителә торган затларның хокуклары һәм бурычлары

1.9.1. Оешма җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле хокуклы:

тикшерү үткәрүдә турыдан-туры катнашуга, тикшерү предметына кирә торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирүгә;

тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлардан, тикшерү предметына кирә торган, № 294-ФЗ Федераль закон нигезендә тапшыру күздә тотылган мәгълүмат алуга;

тикшерү нәтиҗәләре белән танышуга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән танышуы, алар белән, шулай ук тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның аерым гамәлләре белән килешүе яки килешмәве турында күрсәтүгә;

тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның тикшерү үткәргәндә оешма хокукларын, оешманың вазыйфаи затлары хокукларын бозуга китергән гамәлләренә (гамәл кылмау) Россия Федерациясе законы нигезендә административ тәртиптә һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерүгә;

тикшерүгә Россия Федерациясе каршындагы эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне яки Россия Федерациясе субъектында эшмәкәрләр хокукларын яклау буенча Вәкаләтле вәкилне җәлеп итүгә.

1.9.2. Оешма җитәкчесе һәм вазыйфаи затлары бурычлы:

тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан соралган документларны һәм материалларны, шулай ук тикшерү предметына кирә торган мәсьәләләр буенча телдән һәм язмача аңлатмаларны тапшыруга;

тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның оешма бинасына һәм башка хезмәт бүлмәләренә комачаулыксыз керүләре-булуларын тәэмин итүгә;

мәҗбүри таләпләрне үтәү чараларын оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы булган оешманың вазыйфаи затларының яки вәкаләтле вәкилләренең булуын тәэмин итүгә.

1.10. Дәүләт функциясен үтәүнең нәтиҗәсе булып эш бирүченең халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозуын ачыклау яки бозуларга юл куймавын ачыклау тора.

1.11. Дәүләт функциясен үтәү белән тәгалләнә торган юридик факторлар булып тора:

тикшерү акты (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган тикшерү актының типовой формасы нигезендә);

халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау нигезендә закон бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмә (бозу факты ачыкланган очракта) (үрнәк формасы бу Административ регламентка № 1 кушымтада китерелгән);

беркетмә:

РФ КоАП 5.42 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу турында (бозу факты ачыкланган очракта);

РФ КоАП 19.7 статьясында күздә тотылган административ хокук бозу турында (бозу факты ачыкланган очракта);

тикшерүләр учеты журналына үткәрелгән күчмә тикшерү турында язу (тикшерүләр учеты журналы формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының № 141 боерыгы белән расланган).

Дәүләт функциясен үтәүгә нигез булып Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән хосусый эшмәкәрләрдән, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) мәгълүмат алыну торган очракта, дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә № 59-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

## 2. Дәүләт функциясен үтәү тәртибенә карата таләпләр

### 2.1. Дәүләт функциясен үтәү турында мәгълүмат җиткерү тәртибе

2.1.1. Бу Административ регламент "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – "Интернет" челтәре) Министрлыкның рәсми сайтына (http://mtsz.tatarstan.ru) урнаштырыла.

2.1.2. Министрлыкның урнашу урыны: Казан ш., Волгоград ур., 47 й., тел.: (843) 557-20-01, факс 523-90-74.

2.1.3. Дәүләт функциясен үтәү мәсьәләләре буенча Министрлыкка документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420044, Казан ш., Волгоград ур., 47 й.

Мөрәҗәгатьләрне җибәрү өчен электрон адрес: E-mail:mtsz@tatar.ru.

2.1.4. Министрлыкның эш графигы: шимбә, якшәмбе һәм эш көне булмаган бәйрәм көннәреннән тыш, көн саен, 9.00 дән 18.00 сәгатькәчә (җомга – 16.45 сәгатькәчә), төшке аш вакыты: 12.00 дән 12.45 сәгатькәчә.

2.1.5. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең урнашу урыннары, аларның телефоннары 1 таблицада китерелгән.

1 таблица. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре турында мәгълүматлар

| Ведомство карамагындагы учреждение | Адресы | Телефоны |
|---|---|---|
| "Казан ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ГКУ | 420034, Казан ш., Декабристлар ур., 81 й., А. корп. | (8-843) 562-48-33 |
| Казан ш. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Совет районы буенча филиалы | 420029, Казан ш., Журналистлар ур., 13а й. | (8-843) 273-85-03 |
| "Авиатөзелеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ГКУ | 420037, Казан, Лукин ур., 47а й., | (8-843) 571-67-67 |
| "Вахитов районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге" ГКУ | 420059, Казан ш., Павлюхин ур., 102 й. | (8-843) 277-52-93 |

| | | |
|---|---|---|
| “Киров районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420032, Казан ш., Слобода ур., 23 й. | (8-843) 554-77-36 |
| “Мәскәү районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420039, Казан ш., Гагарин ур., 46 й. | (8-843) 543-75-22 |
| “Яңа Савин районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420044, Казан ш., Ибраһимов ур., 41 й. | (8-843) 543-19-52 |
| “Идел буе районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 420101, Казан ш., Бертуган Касыймовлар ур., 22/7 | (8-843) 224-86-66 |
| “Азнакай ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423330.Азнакай ш., Солтангалиев ур., 33 й. | (8-85592) 7-57-00 |
| “Әлмәт ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423450, Әлмәт ш., Герцен ур., 86а й. | (8-8553) 32-34-90 |
| “Баулы ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423930, Баулы ш., Энгельс ур., 56 й. | (8-85569) 5-62-29 |
| “Бөгелмә ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423230, Бөгелмә ш., Октябрь ур., 15 й. | (8-85594) 4-17-60 |
| “Буа ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422430, Буа ш., Р. Люксембург ур., 159 й. | (8-84374) 3-35-89 |
| “Алабуга ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423600, Алабуга ш., Большая Покровская ур., 33 й. | (8-85557) 7-58-58 |
| “Зәй ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423520, Зәй ш., Нефтьчеләр пр., 37б й. | (8-85558) 7-15-43 |
| “Зеленодол ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422550, Зеленодол ш., Татарстан ур., 1 й. | (8-84371) 5-64-90 |
| “Лениногорск ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423250, Лениногорск ш., Гагарин ур., 51 й. | (8-85595) 5-59-70 |
| “Чаллы ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423831, Чаллы ш., Сөембикә пр., 47 й. | (8-8552) 52-42-68 |
| Чаллы ш. Хлыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Тукай районы буенча филиалы | 423800 Чаллы ш., Яңа шәһәр, Сөембикә пр., 47(43/20) й. | (8-8552) 52-42-68, 52-97-06 |
| “Түбән Кама ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423570, Түбән Кама ш., Төзүчеләр пр., 6а й. | (8-8555) 42-40-79 |
| “Нурлат ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423040, Нурлат ш., Хәмәдиев ур., 19 й. | (8-84345) 2-46-32 |
| “Чистай ш. халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422980, Чистай ш., К. Маркс пр., 35 й. | (8-84342) 5-13-34 |
| “Аксубай районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423060, Аксубай ш.т.б., Романова ур., 6 й. | (8-84344) 2-74-61 |
| “Актаныш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423740, Актаныш ав, Ленина пр., 61 й. | (8-85552) 3-09-83 |
| “Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422900, Алексеевск б., Ленин ур., 87 й. | (8-84341) 2-59-00 |
| “Әлки районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422870, Әлки районы, Базарлы Матак ав., Совет ур., д. 8 | (8-84346) 2-15-21 Факс: (8-84346) 2-15-89 |
| “Апас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422350, Апас ш.т.б., Шоссе ур., 5 й. | (8-84376) 2-12-15 |

| | | |
|---|---|---|
| “Арча районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422000, Арча ш.т.б. Банк ур., 6В й. | (8-84366) 3-29-33 |
| “Әтнә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422750, Олы Әтнә ав., Совет ур, 63 й. | (8-84369) 2-16-50 |
| “Балтач районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422250, Балтач ш.т.б., Совет ур., 16 й. | (8-84368) 2-52-34 |
| “Югары Ослан районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422570, Югары Ослан ав., Медгородок ур., 1 й. | (8-84379) 2-24-28 |
| “Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422700, Биектау ав., Үзәк ур, 7 й. | (8-84365) 2-38-21 |
| “Чүпрәле районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422470, Иске Чүпрәле ав., Колхоз ур., 5 й. | (8-84375) 2-24-51 |
| “Кайбыч районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422330, Олы Кайбыч ав., Кояшлы Бульвар ур., 7 й. | (8-84370) 2-10-06 |
| “Кукмара районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422110, Кукмара б., Ворошилов ур., 2 й, | 8-84364) 2-67-54 |
| “Лаеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422610, Лаеш ш., Беренче Май ур., 16 й. | (8-84378) 2-61-02 |
| “Мамадыш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422190, Мамадыш ш., Муса Җәлил ур., 12 й. | (8-85563) 3-35-57 |
| “Менделеев районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423650, Менделеев ш., Фомин ур., 19 й. | (8-85549) 2-02-02 |
| Менделеев районы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Әгеҗе районы буенча филиалы | 422230, Әгерҗе ш., Сәетов ур., 8а й. | (8-85551) 2-31-73, 2-29-84 |
| “Минзәлә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423700, Минзәлә ш., Ленин ур., 78 й. | (8-85555) 3-23-80 |
| “Мөслим районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423970, Мөслим ав., Пушкин ур., 47 й. | (8-85556) 2-49-50 |
| “Яңа Чишмә районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423119, Яңа Чишмә ав., Ленин ур., 93 й. | (8-84348) 2-30-42 |
| “Питрәч районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422770, Питрәч ав., Совет ур., 34 й. | (8-84367) 3-04-84 |
| “Балык Бистәсе районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422650, Балык Бистәсе ш.т.б., Ленин ур., 48 й. | (8-84361) 2-21-81 |
| “Саба районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422060, Байлар Сабасы ш.т.б., Тукай ур., 87 й. | (8-84362) 2-44-11 |
| “Сарман районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423350, Сарман ав., М.Җәлил ур., 63 й. | (8-85559) 2-42-62 |
| “Спас районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422840, Спас районы, Болгар ш., Хирурга Шеронов ур., 21 й. | (8-84347) 3-07-72 |
| “Тәтеш районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422370, Тәтеш ш., Ирек м., 45 й. | (8-84373) 2-63-29 |
| Тәтеш районы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең Кама Тамагы районы буенча филиалы | 422820, Кама Тамагы ш.т.б., К. Маркс ур., 2а й. | (8-84377) 2-14-67, 2-18-84 |
| “Теләче районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 422080, Теләче ав., Ленин ур., 73 й. | (8-84360) 2-13-51 |
| “Чирмешән районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423100, Чирмешән ав., Титова ур., 5 й. | (8-84396) 2-54-59 |

| | | |
|---|---|---|
| “Ютазы районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге” ГКУ | 423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин ур., 38 й. | (8-5593) 2-60-16 |

2.1.6. Министрлыкның һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең урнашу урыннары, телефоннары һәм эш графиклары турында мәгълүматны алып була:

Министрлык телефоннары (557-20-01, 557-21-13), бу Административ регламентның 1 таблицасында күрсәтелгән халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре телефоннары аша;

Министрлыкның “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтында (http://mtsz.tatarstan.ru);

Министрлык, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре биналарындагы мәгълүмати стендлардан.

2.1.7. Бу Административ регламент турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында ((http://mert.tatarstan.ru) урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентларының бердәм реестрына кертелә.

2.1.8. Дәүләт функциясе һәм аны үтәү тәртибе турыда мәгълүмат бирү, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, электрон элемтә яки телефон элемтәсеннән (автомат төстә мәгълүмат бирүне кертеп), “Интернет” челтәреннән (“Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы” федераль дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – Бердәм портал) һәм (яки) төбәк порталын – “Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы” ((http://uslugi.tatar.ru) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы) кертеп), файдалану нигезендә, турыдан-туры Министрлык һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәге биналарында хәл ителә.

**2.2. Эш бирүчеләрдән күзәтчелек һәм контрольлек чаралары өчен түләү алуга юл куймау**

Эш бирүчеләрдән күзәтчелек һәм контрольлек чаралары өчен түләү алынмый, шул исәптән, тикшерү үткәрүгә җәлеп ителгән очракта, экспертлар һәм эксперт оешмалары тарафыннан хезмәт күрсәтүгә.

**2.3. Дәүләт функциясен үтәү срогы**

2.3.1. Планлы күчмә тикшерү үткәрү срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш.

Планлы документлар тикшерү үткәрү срогы 15 эш көненнән артмаска тиеш.

Планнан тыш тикшерү үткәрү срогы 10 эш көненнән артмаска тиеш.

Планнан тыш документлар тикшерү үткәрү срогы 15 эш көненнән артмаска тиеш.

2.3.2. Тикшерүләр үткәрү сроклары Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы җитәкчесе карары белән озайтылырга мөмкин, әмма күп дигәндә 15 эш көненә генә.

2.3.3. Бер оешмага планлы тикшерү өч елга күп дигәндә бер тапкыр үткәрелә.

**2.4. Тикшерүләр үткәрүгә нигезләр**

2.4.1. Планлы тикшерүләр Министрлык тарафыннан эшләнелә торган еллык планнар нигезендә үткәрелә. Планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнары (алга таба – Планнар), №294-ФЗ Федераль закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокта, прокуратура органнары белән килештерелергә тиеш. Министр тарафыннан расланыла торган Планнар Министрлыкның "Интернет" челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

Оешманы еллык планга кертү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

оешма тарафыннан инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүмат тапшырылмаганда;

инвалидларны эшкә алу өчен квота үтәлмәгәндә;

оешманың дәүләт теркәвенә алынуына өч ел үткәч,

гражданнардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый оешмалардан, башка органнардан һәм оешмалардан билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тарту турында мәгълүмат кергәндә;

оешмага карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерү тәгалләнүгә өч ел узгач;

алдагы тикшерү барышында ачыкланган бозулар һәм аларны юкка чыгару нәтиҗәләре;

күрсәтмәләрне үтәү һәм күрсәтмәләрне үтәү срокларына сыешу.

2.4.2. Планнан тыш күчмә яки планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:

мәҗбүри таләпләрне бозуларны (ачыкланган) юкка чыгару турында элек бирелгән күрсәтмәнең оешма тарафыннан үтәү срогы чыкканда;

гражданнардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый оешмалардан, башка органнардан һәм оешмалардан билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тарту турында мәгълүмат кергәндә;

элек ачыкланган бозуларны юкка чыгаруның гомуми юрисдикция суды карары нигезендә билгеләнгән срогы чыкканда;

прокуратура органнарына алынган материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнар үтәлешенә күзәтчелек кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турында прокурор таләпләре.

Министрлыкка мөрәҗәгать иткән затны билгеләү мөмкинлеге бирмәгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук югарыда күрсәтеп үтелгән фактлар турында мәгълүматлар урын алмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигез булып хезмәт итә алмый.

**2.5. Күзәтчелек һәм контрольлекне турыдан-туры хәл итүче вазыйфаи затлар**

Дәүләт функциясен үтәүгә вәкаләтле Министрлыкның вазыйфаи затлары исемлеге Министрлыкның 12.11.2007 ел, №346 боерыгы белән билгеләнгән.

**2.6. №294-ФЗ Федераль законны бозган өчен оешмаларның җаваплылыгы**

№294-ФЗ Федераль законны бозуга юл куйган, тикшерүләр үткәрүгә нигезсез комачаулаган, тикшерүләрдән качарга маташкан һәм (яки) ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында Министрлык күрсәтмәләрен билгеләнгән срокта үтәмәгән оешмалар, аларның җитәкчеләре, оешмаларның башка вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

**2.7. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының тикшерү үткәрүдә җаваплылыгы**

2.7.1. Министрлык, аның вазыйфаи затлары, тикшерү үткәргәндә вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәгәндә, хокукка каршы гамәлләр кылганда Россия Федерациясе законы нигезендә җавап бирә.

2.7.2. Россия Федерациясе законын бозган гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында Министрлык мондый чаралар күрелгәннән соң ун көн эчендә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре санга сугылмаган оешмага язмача хәбәр итәргә тиеш.

## 3.Тикшерелә торган оешмаларга карата куела торган мәҗбүри таләпләр

Юридик затларга карата куелып, үтәлеше контрольдә тотыла торган мәҗбүри таләпләр, аларны билгеләүче норматив-хокукый актлар исемлеге, тикшерү үткәрелгәндә юридик затлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге 2 таблицада китерелгән.

2 таблица – Оешмаларга (юридик затларга) карата куела торган мәҗбүри таләпләр исемлеге

| **Мәҗбүри таләпләр исемлеге** | **Мәҗбүри таләпне билгеләүче норматив-хокукый акт** | **Тикшерү үткәрелгәндә юридик затлар тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар** |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Эш бирүчеләр билгеләнгән квоталар нигезендә, квоталар кертелгәннән соң бер ай эчендә аларны бирергә, кирәк булган очракта, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын, махсус эш урыннарының минималь санын һәм инвалидлар өчен резервлана торган эш урыннарын булдырырга, | №181-ФЗ Федераль законның 24 статьясындагы икенче өлеше; №60-ТРЗ ТР Законының 3,6 статьялары; ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында | Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын булдыру турында боерыкның оешма раслаган күчермәсе |

| | | |
|---|---|---|
| шулай ук әлеге эш урыннары турында мәгълүматлардан торган локаль норматив актлар кабул итәргә тиеш. | нигезләмәнең 3.1 пункты | |
| 2. Эш бирүчеләр, инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә, инвалидалга хезмәт шартлары тудырырга тиеш | №181-ФЗ Федераль законның 24 статьясындагы икенче өлеше;<br>№60-ТРЗ ТР Законының 6 статьясы;<br>ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәнең 3.1 пункты | Эш бирүченең инвалидны реабилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә махсус хезмәт шартлары күздә тотылган локаль норматив актлары |
| 3. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә ай саен инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен буш эш урыннарының һәм вакантлы вазыйфаларның, булдырылган яки бирелгән эш урыннарының булуы турында мәгълүмат, әлеге эш урыннары турында мәгълүматлардан торган локаль норматив актлар, инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүматны кертеп, тапшыру | №181-ФЗ Федераль законның 24 статьясындагы икенче өлеше;<br>№1032-1 Россия Федерациясе Законының 25 статьясындагы 3 п.;<br>№60-ТРЗ ТР Законының 3,6 статьялары;<br>ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәнең 3.1 пункты;<br>№1032-1 Россия Федерациясе Законының 25 статьясындагы өченче өлеше;<br>№60-ТРЗ ТР Законының 6 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты | ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә №3 кушымта нигезендәге форма буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрү турында хатның (белдерү кәгазе) оешма раслаган күчермәсе |
| 4. Инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү (билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тартуларның булмавы) | №1032-1 Россия Федерациясе Законының 25 статьясындагы өченче өлеше;<br>№60-ТРЗ ТР Законының 6 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты | Инвалидны инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квота чикләрендә бирелгән һәм (яки) булдырылган эш урыннарына эшкә алу турында боерыкның оешма тарафыннан расланган күчермәсе |

| | | |
|---|---|---|
| 5. Эш бирүчеләр тарафыннан хезмәткәр эшеннән киткәннән соң ун көн эчендә халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә бушаган эш урыннары, билгеләнгән квоталар чикләрендә бирелгән яки булдырылган эш урыннары турында мәгълүмат тапшыру | №60-ТРЗ ТР Законының 6 статьясындагы 2 өлешенең 2.1 пункты;<br>ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәнең 3.2 пункты | ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә №4 кушымта нигезендәге форма буенча халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрү турында хатның (белдерү кәгазе) оешма раслаган күчермәсе |
| 6. Оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү (квотаны үтәү мөмкинлегенә ия булмау), хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саны, оешмада эшләүче инвалидлар саны, җитештерүнең характеры (шартлау һәм янгын чыгу куркынычы булган, зарарлы һәм авыр хезмәт шартлары, технологик процессның өзексезлегенә бәйле сменалы эш, хезмәтне саклау таләпләрен үтәү) | №181-ФЗ Федераль законның 24 статьясы;<br>ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәнең 2.3, 2.11 пунктлары | Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрү турында хатның (белдерү кәгазе) оешма раслаган күчермәсе:<br>- инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүмат;<br>- ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә №2 кушымта нигезендәге форма буенча квотаны үтәү мөмкинлегенә ия булмау турында мәгълүмат;<br>– ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә №1 кушымта нигезендәге форма буенча мәгълүмат |

## 4. Тикшерү үткәрелгәндә оешма тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар

Тикшерү үткәрү максатына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге, шулай ук аларны билгели торган норматив-хокукый актлар 3 таблицада китерелгән.

3 таблица – Тикшерү үткәрү максатына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| Тикшерү үткәрелгәндә тапшырыла торган документ | Документ формасын билгели торган норматив-хокукый акт |
|---|---|
| 1. Инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын бирү, кирәк булган очракта, эш урыннарын булдыру турында боерыкның оешма тарафыннан расланган күчермәсе | – |
| 2. Инвалидны инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квота чикләрендә бирелгән һәм (яки) булдырылган эш урыннарына эшкә алу турында боерыкның оешма тарафыннан расланган күчермәсе | – |
| 3. Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан баш тарту турында боерыкның оешма тарафыннан расланган күчермәсе | – |
| 4. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә түбәндәге мәгълүматларны:<br>- хезмәткәрләрнең исемлектәге уртача саны, оешмада эшләүче инвалидлар саны, җитештерүнең характеры (шартлау һәм янгын чыгу куркынычы булган, зарарлы һәм авыр хезмәт шартлары, технологик процессның өзексезлегенә бәйле сменалы эш, хезмәтне саклау таләпләрен үтәү);<br><br>- квотаны үтәү мөмкинлегенә ия булмауның объектив шартлары (сәбәпләре) турында;<br><br>- инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квота чикләрендә эш урыннарын бирү һәм (яки) булдыру турында | ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә №1 кушымта<br><br>ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә №2 кушымта<br><br>ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә №3 кушымта<br><br>ТР МК №170 карары белән расланган Татарстан Республикасы |

| | |
|---|---|
| - билгеләнгән квотлар кысаларында бирелеп, бушап калучы эш урыннары турында мәгълүматны җибәрү хакында хатның (белдерү кәгазе) оешма тарафыннан расланган күчермәсе | территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау тәртибе турында нигезләмәгә №3 кушымта |
| 5. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүмат җибәрү хакындагы хатның (белдерү кәгазе) оешма тарафыннан расланган күчермәсе | – |

## 5. Административ процедуралар (гамәлләр) составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләр) электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре

Дәүләт функциясе түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

планлы күчмә һәм планлы документлар тикшерүләрне планлаштыру һәм әзерләү;

планлы күчмә тикшерү үткәрү;

планлы документар тикшерү үткәрү;

планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү;

планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү;

планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозу фактлары булганда тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү.

Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы бу Административ регламентка №2 кушымтада китерелгән.

Дәүләт функциясен үтәүне туктатып торуга нигезләр күздә тотылмаган.

### 5.1. “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү”

5.1.1. “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасын башлауга нигез булып еллык Планны әзерләү һәм аның проектын, килештерү өчен, прокуратура органнарына җибәрү срокларының җитүе тора.

5.1.2. Министрлыкның халыкны эш белән тәэмин итүнең актив формаларын үстерү бүлеге начальнигы еллык Планны әзерләү өчен җаваплы эш башкаручыны (җаваплы эш башкаручылар) (алга таба – Планны әзерләү буенча җаваплы эш башкаручы) билгели.

5.1.3. Планны әзерләү буенча җаваплы эш башкаручы “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

– Россия Федерациясе Хөкүмәтенең №489 карары белән расланган Дәүләт контрольлеге (күзәтчелек) һәм муниципаль контрольлек органнары тарафыннан юридик затларга һәм хосусый эшмәкәрләргә планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрендә күздә тотылган форма буенча еллык План проектын әзерли, аны Бүлекләр начальниклары, министр белән килештерә;

үтәү срогы: планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәр килгән елның 23 августыннан да соңга калмыйча;

– планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәр килгән елның 1 сентябренә кадәр прокуратура органына, килештерү өчен, кәгазьдә еллык План проектын (электрон рәвештәге күчермәсе белән) почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки “Электрон имза турында” Федераль закон нигезендә көчәйтүле квалификацияләнгән электрон имза (алга таба – көчәйтүле квалификацияләнгән электрон имза) белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә;

– прокуратура органы белән килештерелгән еллык Планның, планлы тикшерүләр үткәрү елына кадәр килгән елның 1 ноябренә кадәр, министр тарафыннан раслануын һәм прокуратура органына җибәрелүен тәэмин итә;

– еллык Планны агымдагы календарь елының 31 декабренә кадәр Министрлыкның рәсми сайтына урнаштыруны тәэмин итә.

5.1.4. Министрлыкның халыкны эш белән тәэмин итүнең актив формаларын үстерү бүлеге начальнигы (кирәк булган очракта – Министрлыкның юридик бүлеге начальнигы), План нигезендә оешмага тикшерү үткәрү өчен, тиешле Бүлекнең вазыйфаи затлары арасыннан җаваплы эш башкаручыны (җаваплы эш башкаручылар) билгели.

Үтәү срогы: оешмага тикшерү үткәрүне башлаганчы күп дигәндә өч атна кала яки турыдан-туры планны төзегәннән соң.

5.1.5. Җаваплы эш башкаручы “Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен хәл итә:

Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган тикшерү үткәрү турында боерыкның типовой формасы нигезендә тикшерү үткәрү турында боерык проектын әзерли – аны үткәрүгә күп дигәндә 2 атна кала.

Тикшерү үткәрү турында боерыкта күрсәтелә:

дәүләт функциясен үтәүче Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органы атамасы;

тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның, шулай ук тикшерү үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре, вазыйфалары;

тикшерелә торган оешманың атамасы, оешманың урнашу урыны;

тикшерү максатлары, бурычлары, предметы һәм аны үткәрү сроклары;

тикшерү үткәрүнең хокукый нигезләре, шул исәптән тикшерүгә карата мәҗбүри таләпләр;

тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле контрольлек чараларын үткәрү сроклары һәм исемлеге;

дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентлар исемлеге;

тикшерү үткәрү максатларына һәм бурычларына ирешү өчен кирәкле булып, оешма тарафыннан тапшырылырга тиешле документлар исемлеге;

тикшерү үткәрүне башлау һәм төгәлләү датасы.

– тикшерү үткәрү турында боерыкның министр тарафыннан имзалануын тәэмин итә;

– оешма җитәкчесенә тикшерү үткәрү турында белдерү кәгазен җибәрүне (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән), яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яисә электрон почта аша) тәэмин итә – тикшерү үткәрүне башлау датасына кадәр күп дигәндә 7 көн кала;

бу пунктны үтәү срогы: күп дигәндә өч эш көне эчендә.

5.1.6. Җаваплы эш башкаручы планлы документлар тикшерүне планлаштырганда һәм әзерләгәндә түбәндәге административ процедураларны хәл итә:

тикшерү үткәрүне башлаганчы ике атналык срок эчендә, инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган мәгълүматларны анализлый;

оешма тарафыннан инвалидларны эшкә алу өчен бирелгән (булдырылган) эш урыннары (шул исәптән махсус) саны, оешмада чынбарлыкта эшләүче инвалидларның саны, инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарының расчет саны турында мәгълүматлардан торган, Министрлыкка тапшырылырга тиешле материаллар һәм документлар исемлеген билгели;

тикшерү үткәрү өчен кирәкле материалларның һәм документларның оешма тарафыннан тапшырылуы турында запрос (таләп) проектын әзерли;

тикшерү үткәрү өчен кирәкле материалларның һәм документларның оешма тарафыннан тапшырылуы турында запрос (таләп) проектын тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи зат белән килештерүне тәэмин итә;

тикшерү үткәрү өчен кирәкле материалларның һәм документларның оешма тарафыннан тапшырылуы турында запросны (таләп) министрга имза салуга тапшыра;

тикшерү үткәрү өчен кирәкле материалларның һәм документларның оешма тарафыннан тапшырылуы турында запросны оешма җитәкчесенә җибәрүне (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән), яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яисә электрон

почта аша) тәэмин итә – тикшерү үткәрүне башлау датасына кадәр күп дигәндә 7 көн кала;

бу пунктны үтәү срогы: күп дигәндә биш эш көне эчендә.

5.1.7. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планлы күчмә һәм планлы документлар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү буенча карар кабул итүнең критерие булып бу Административ регламентның 2.4.1. пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.1.8. "Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү" административ процедурасының нәтиҗәсе булып оешма җитәкчесенә түбәндәгеләрне җибәрү тора:

планлы күчмә тикшерү үткәргәндә – планлы күчмә тикшерү үткәрү турында боерык (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган тикшерү үткәрү турында боерыкның типовой формасы нигезендә) күчермәсе белән, тикшерү үткәрү турында белдерү кәгазе;

планлы документлар тикшерү үткәргәндә – планлы документлар тикшерү үткәрү өчен кирәкле булып, оешма тарафыннан материаллар һәм документларның тапшырылуы турында запрос.

5.1.9. "Планлы күчмә һәм планлы документар тикшерүләр үткәрүне планлаштыру һәм әзерләү" административ процедурасын үтәү нәтиҗәсен теркәү, Министрлыкта канцелярия эшләре кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә, бу Административ регламентның 5.1.8 пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазе, боерык яки запрос күчермәләрен учетка алу һәм дело материалларында саклау, шулай ук әлеге документларны электрон рәвештә, аерым саклау юлы белән хәл ителә.

### 5.2. "Планлы күчмә тикшерү үткәрү" административ процедурасы

5.2.1. Планлы күчмә тикшерү үткәрү" административ процедурасын башлауга нигез булып тиешле оешманы оешмаларга тикшерүләр үткәрү буенча Министрлыкның еллык Планына кертү тора, шулай ук документлар тикшерү вакытында түбәндәгеләргә ирешеп булмау тора:

оешманың эшмәкәрлек эшчәнлегенең аерым төрләрен хәл итүне башлавы турында белдерү кәгазендәге мәгълүматларның һәм оешманың Министрлык карамагындагы башка документларындагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген раслый алмау;

тиешле контрольлек чарасы үткәрмичә генә оешма эшчәнлегенең мәҗбүри таләпләргә туры килүен бәяли алмау.

5.2.2. Җаваплы эш башкаручы "Планлы күчмә тикшерү үткәрү" административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен хәл итә:

– Министрлык боерыгы белән билгеләнгән срокта оешмага килә:

– хезмәт таныклыгын күрсәтеп, оешма җитәкчесенә тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсен тапшыра;

үтәү срогы: оешмага килүгә үк;

– оешма җитәкчесенә тикшерү үткәрүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольлек чаралары төрләре һәм күләме турында, аны үткәрү сроклары һәм шартлары турында җиткерә;

үтәү срогы: оешмага килүгә үк;

– документларда тикшерү максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле булган мәгълүматларны өйрәнә;

– оешманың түбәндәге нигезләмәләрне (тикшерү үткәргәндә оешмага карата бу Административ регламентның 2 таблицасы нигезендә куела торган мәҗбүри таләпләр) үтәвен тикшерә:

инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бирелгән эш урыннары санының халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон таләпләренә туры килүен;

фактта эшләүче инвалидлар санының инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарының расчет санына туры килүен;

оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган, билгеләнгән срокларда инвалидларны һөнәри реабилитацияләү һәм эшкә урнаштыруга ярдәм итү эшчәнлеген хәл кылу өчен кирәкле мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген;

оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган, билгеләнгән срокларда инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген;

– кирәк булганда, планлы күчмә тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча документлар һәм материалларны, шулай ук оешма җитәкчесенең һәм язмача аңлатмаларын соратып ала, оешма җитәкчесе һәм /яки оешма хезмәткәрләре белән тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча әңгәмәләр кора;

– тикшерү предметына керүче мәсьәләләр буенча тапшырылган документларны, материалларны һәм аңлатмаларны анализлый һәм халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуларның булуы (булмавы) турында карар кабул итә;

– бозу фактлары ачыкланганда:

бозу фактларын раслаучы документлар (алга таба – раслау документлары) күчермәләрен билгеләнгән тәртиптә әзерли һәм раслый;

тикшерү акты проектына халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә закон бозу фактлары турында мәгълүматлар кертә, раслау документлары күчермәләре белән;

– тикшерүләр учеты журналына (тикшерүләр учеты журналының типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган) Министрлыкның атамасы, тикшерү үткәрүне башлау һәм төгәлләү даталары, аны үткәрү сроклары, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы, тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, атасының исемнәре һәм

вазыйфалары турында мәгълүматларны язып куя һәм әлеге язуны тикшерү үткәрүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның имзалары белән раслый;

– оешмада тикшерүләр учеты журналы булмаганда, мәгълүматларны тикшерү акты проектына язып куя;

– тикшерү акты проектын (тикшерү акты проектының типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган) әзерли, тикшерү үткәрелгәндә оешма җитәкчесе тарафыннан тапшырылган документлар исемлеге һәм күчермәләре (алга таба – кушымталар) белән бергә акт проектын тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә тапшыра;

үтәү срогы: турыдан-туры тикшерү тәмамланганнан соң;

– 2 нөсхәдә тикшерү актын имзалый;

үтәү срогы: турыдан-туры акт төзелгәннән соң;

– тикшерү актының бер нөсхәсен, кушымталарының күчермәләре белән, оешма җитәкчесенә имза салуга тапшыра;

үтәү срогы: турыдан-туры актка кул куелганнан соң;

– оешма җитәкчесе кая да булса киткән очракта, шулай ук оешма җитәкчесе тикшерү актын кабул итүдән баш тарткан очракта актны почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: турыдан-туры актка кул куелганнан соң;

– тикшерү актының икенче нөсхәсенә тиешенчә язып куя, почта аша заказлы хатны тапшыру турында уведомлениене шуңа теркәп куя;

үтәү срогы: турыдан-туры тикшерү актын почта аша заказлы хат белән җибәргәннән соң;

– оешма җитәкчесе тикшерү актының эчтәлеге белән килешмәгән очракта, тикшерү актына оешма җитәкчесенең язмача каршы килүләре теркәп куела;

үтәү срогы: турыдан-туры оешма җитәкчесенең каршы килүләре алынганнан соң;

– тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары урын алганда, бу Административ регламентның 5.7.2 пунктында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл кыла.

5.2.3. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планлы күчмә тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча карар кабул итүнең критерие булып тикшерү үткәрелгәндә тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.2.4. “Планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуларның урын алуын яки закон бозуларның булмавын ачыклау тора.

5.2.5. “Планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе тикшерү актында, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.2.6. “Планлы күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү срогы – күп дигәндә 10 көн эчендә.

**5.3. “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы**

5.3.1. “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып тиешле оешманы еллык Планга кертү тора. План Министрлыкның Интернет челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырыла.

5.3.2. Җаваплы эш башкаручы “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен хәл итә:

– түбәндәге нигезләмәләрнең (тикшерү үткәргәндә оешмага карата бу Административ регламентның 2 таблицасы нигезендә куела торган мәҗбүри таләпләр) үтәлешен тикшерү максатыннан, оешмадан алынган материалларны һәм документларны өйрәнә:

инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота нигезендә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен булдырылган яки бирелгән эш урыннары санының халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон таләпләренә туры килүен;

фактта эшләүче инвалидлар санының инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарының расчет санына туры килүен;

оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган, билгеләнгән срокларда инвалидларны һөнәри реабилитацияләү һәм эшкә урнаштыруга ярдәм итү эшчәнлеген хәл кылу өчен кирәкле мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген;

оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә тапшырылган, билгеләнгән срокларда инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген;

– тапшырылган документларда хаталар һәм/яки каршылыклы фикерләр ачыкланганда яисә документлардагы мәгълүматлар Министрлык карамагындагы документлардагы мәгълүматларга туры килмәгәндә, оешма җитәкчесенә (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән), яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яисә электрон почта аша) оешманың Министрлыкка тикшерү үткәрү өчен кирәкле өстәмә материалларны һәм документларны тапшырырга тиешлеге турында запрос (таләп) җибәрә;

– оешма тарафыннан тапшырылган аңлатмалардан чыгып, материалларны һәм документларны анализлый һәм халыкны эш белән

тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуларның булуы (булмавы) турында карар кабул итә;

– тикшерү акты проектын әзерли, аңа кушымталарын теркәп куя, тикшерү акты проектын тикшерү үткәрүгә җаваплы вазыйфаи затка карап тикшерүгә тапшыра;

үтәү срогы: турыдан-туры тикшерү тәмамланганнан соң;

– 2 нөсхәдә тикшерү актын имзалый;

үтәү срогы: турыдан-туры акт рәсмиләштерелгәннән соң;

– тикшерү актының бер нөсхәсен оешма җитәкчесенә танышуга җибәрә (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән), яки факсимиль элемтә чараларыннан файдаланып яисә электрон почта аша);

үтәү срогы: турыдан-туры акт рәсмиләштерелгәннән соң һәм актка кул куелганнан соң;

– оешма җитәкчесе тикшерү актының эчтәлеге белән килешмәгән очракта, тикшерү актына оешма җитәкчесенең язмача каршы килүләре (булган очракта) теркәп куела;

үтәү срогы: турыдан-туры оешма җитәкчесенең каршы килүләре алынганнан соң;

– тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары урын алганда, бу Административ регламентның 5.7.2 пунктында күздә тотылган административ гамәлләрне хәл кыла.

5.3.3. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планлы документар тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча карар кабул итүнең критерие булып тикшерү үткәрелгәндә тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.3.4. “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуларның урын алуын яки закон бозуларның булмавын ачыклау тора.

5.3.5. “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасының нәтиҗәсе тикшерү актында, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында электрон рәвештә теркәлә.

5.3.6. “Планлы документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү срогы – күп дигәндә 15 көн эчендә.

### 5.4. “Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасы

5.4.1 “Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасын башлауга нигез булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.4.2. Министр тикшерү үткәрү турында карар кабул итә һәм Министрлыкның халыкны эш белән тәэмин итүнең актив формаларын үстерү бүлеге начальнигына (кирәк булганда – Министрлыкның юридик бүлеге начальнигы) тикшерү үткәрергә куша.

Үтәү срогы: планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканнан соң бер көн эчендә.

5.4.3. Министрлыкның халыкны эш белән тәэмин итүнең актив формаларын үстерү бүлеге начальнигы оешмага тикшерү үткәрү өчен тиешле бүлекнең вазыйфаи затлары арасыннан җаваплы эш башкаручыны (җаваплы эш башкаручылар) (алга таба – җаваплы эш башкаручы) билгели.

Үтәү срогы: планнан тыш тикшерү үткәрүгә нигезләр килеп чыкканнан соң бер көн эчендә.

5.4.4 Җаваплы эш башкаручы "Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү" административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен башкара:

– тикшерү үткәрү турында министр тарафыннан карар кабул ителгәннән соң ике көн эчендә тикшерү үткәрү турында боерык (тикшерү үткәрү турында боерыкның типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган) проекты әзерли;

үтәү срогы: күп дигәндә ике эш көне;

– министрның тикшерү үткәрү турында боерыкны имзалавын тәэмин итә;

үтәү срогы: күп дигәндә ике эш көне;

– планнан тыш күчмә тикшерү әзерләгәндә:

оешманың эшчәнлеген хәл итү урыны буенча прокуратура органына, тикшерү үткәрү турында боерыкка кул куелганнан көндә, аның күчермәсе һәм тикшерү үткәрүгә нигез булып торган мәгълүматларны үз эченә алган документлар белән, планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза (планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның типовой формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган) тапшыра яки аны почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки көчәйтүле квалификацияләнгән электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә;

үтәү срогы: тикшерү үткәрү турында боерыкка кул куелган көнне;

планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында прокуратура органы карарын ала;

– оешма җитәкчесенә, тикшерү үткәрү турында боерык күчермәсе белән, тикшерү үткәрү турында белдерү кәгазе (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки факсимиль элемтә аша яисә электрон почта аша) җибәрә;

үтәү срогы: тикшерү үткәрү башланырга күп дигәндә 3 календарь көне кала.

5.4.5. Планнан тыш документлар тикшерү үткәрүгә әзерләнгәндә өстәмә рәвештә бу Административ регламентның 5.1.6 пунктында күздә тотылган гамәлләр башкарыла.

5.4.5. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планнан тыш күчмә һәм планнан документлар тикшерүләр үткәрүне әзерләү буенча карар кабул итүнең критерие булып бу Административ регламентның 2.4.2. пунктында күрсәтелгән очраклар тора.

5.4.7. "Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү" административ процедурасының нәтиҗәсе булып оешма җитәкчесенә түбәндәгеләрне җибәрү тора:

Планнан тыш күчмә тикшерү үткәргәндә – планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерык (Россия Икътисадый үсеш министрлыгының №141 боерыгы белән расланган тикшерү үткәрү турында боерыкның типовой формасы нигезендә) күчермәсе белән, тикшерү үткәрү турында белдерү кәгазе;

планнан тыш документлар тикшерү үткәргәндә – планнан тыш документлар тикшерү үткәрү өчен кирәкле булып, оешма тарафыннан материаллар һәм документларның тапшырылуы турында запрос.

5.4.8. "Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү" административ процедурасын үтәү нәтиҗәсен теркәү, Министрлыкта канцелярия эшләре кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә, бу Административ регламентның 5.4.7 пунктында күрсәтелгән белдерү кәгазе, боерык яки запрос күчермәләрен учетка алу һәм дело материалларында саклау, шулай ук әлеге документларны электрон рәвештә аерым саклау юлы белән хәл ителә.

**5.5. "Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү" административ процедурасы**

5.5.1. "Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү" административ процедурасын башлауга нигез булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очракларның килеп чыгуы һәм "Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү" административ процедурасының төгәлләнүе тора.

5.5.2. Җаваплы эш башкаручы "Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү" административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен хәл итә:

– бу Административ регламентның 5.5.2 пунктындагы 2,3,5 абзацларында күздә тотылган административ гамәлләрне башкара;

– документларда тикшерүнең максатларына, бурычларына һәм предметына бәйле мәгълүматларны өйрәнә, һәм, нигезләргә бәйле рәвештә, тикшерә:

Татарстан Республикасы хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) таләпләрне бозуларны (ачыкланган) юкка чыгару турында элек бирелгән күрсәтмәнең оешма тарафыннан үтәлмәве;

гражданнардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан һәм башка органнардан һәм оешмалардан алынган хәбәрләрдә билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тарту турында мәгълүматлардан торган фактларның бәян ителүе;

элек ачыкланган бозуларны гомуми юрисдикциядәге суд карары белән билгеләнгән срок чыкканнан соң юкка чыгару;

прокуратура органнарына алынган материалларда һәм мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән фактлар;

– бу Административ регламентның 5.2.2 пунктындагы 12-21, 23, 25,27,29 абзацларында күздә тотылган административ гамәлләрне башкара:

–планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне килештерү турында карар кабул иткән прокуратура органына тикшерү акты күчермәсен, имзаланганнан соң 5 эш көне эчендә, җибәрә;

– тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары урын алганда, бу Административ регламентның 5.7.2 пунктында күздә тотылган административ гамәлләрне башкара.

5.5.3. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүнең нәтиҗәләре буенча карар кабул итүнең критерие булып тикшерү үткәрү барышында тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.5.4. “Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасы нәтиҗәсе булып оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуларга юл куелганлыгын яки юл куелмаганлыгын ачыклау тора.

5.5.5. “Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе тикшерү актында, шулай ук электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтында теркәлә.

5.5.6. “Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү срогы – күп дигәндә 10 эш көне эчендә.

## 5.6. “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы

5.6.1. “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын башлауга нигез булып бу Административ регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очракларның килеп чыгуы һәм “Планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрүне әзерләү” административ процедурасының төгәлләнүе тора.

5.6.2. Җаваплы эш башкаручы “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасының түбәндәге административ гамәлләрен хәл итә:

– тикшерү максатында оешмадан алынган материалларны һәм документларны өйрәнә:

Россия Федерациясе субъектының хокукый актларында билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне һәм (яки) таләпләрне бозуларны (ачыкланган) юкка чыгару турында элек бирелгән күрсәтмәнең оешма тарафыннан үтәлүен;

гражданнардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан һәм башка органнардан һәм оешмалардан алынган хәбәрләрдә билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тарту турында мәгълүматлардан торган фактларның бәян ителүен;

элек ачыкланган бозуларның гомуми юрисдикциядәге суд карары белән билгеләнгән срок чыкканнан соң юкка чыгарылуын;

прокуратура органнарына алынган материалларда һәм мөрәҗәгатьләрдә бәян ителгән фактларны;

– бу Административ регламентның 5.3.2 пунктындагы 2-9,11,13,15 абзацларында күздә тотылган административ гамәлләрне башкара:

– тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары урын алганда, бу Административ регламентның 5.7.2 пунктында күздә тотылган административ гамәлләрне башкара.

5.6.3. Җаваплы эш башкаручы тарафыннан планнан тыш документар тикшерү үткәрүнең нәтиҗәләре буенча карар кабул итүнең критерие булып тикшерү үткәрү барышында тапшырылган документларның һәм материалларның халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге законга туры килүе (туры килмәве) тора.

5.6.4. “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасы нәтиҗәсе булып оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуларга юл куелганлыгын яки юл куелмаганлыгын ачыклау тора.

5.6.5. “Планнан тыш документар тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе тикшерү актында, шулай ук электрон рәвештә Министрлыкның рәсми сайтында теркәлә.

5.6.6. “Планнан тыш кучмә тикшерү үткәрү” административ процедурасын үтәү срогы – күп дигәндә 15 эш көне эчендә.

## 5.7. Тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары булганда тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү

5.7.1. “Тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары булганда тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү” административ процедурасын башлауга нигез булып тикшерү актында

халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактларының урын алуы тора.

5.7.2: Җаваплы эш башкаручы түбәндәге административ процедураларны башкара:

– халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуны (ачыкланган) юкка чыгару турында үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмә тутыра һәм аңа кул куя;

үтәү срогы: турыдан-туры тикшерү тәгәлләнгәннән соң;

– халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуны (ачыкланган) юкка чыгару турында үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмәне тапшыра;

үтәү срогы: турыдан-туры күрсәтмә рәсмиләштерелгәннән соң, тикшерү акты белән бер үк вакытта.

5.7.3. Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты түбәндәге административ процедураларны башкара:

– административ хокук бозу турында эш кузгата, беркетмә проектын эшли:

РФ КоАП 5.42 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу турында;

РФ КоАП 19.7 статьясында күздә тотылган административ хокук бозу турында;

үтәү срогы: административ хокук бозу ачыкланганнан соң ук кичекмәстән;

– үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылып килә торган оешма җитәкчесенә административ хокук бозуга юл куелганлыгы, административ хокук бозу турында беркетмә тутыру датасы һәм урыны турында белдерү кәгазе җибәрүне (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки факсимиль элемтә аша яисә электрон почта аша) тәэмин итә;

үтәү срогы: күп дигәндә 10 эш көне;

– үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылып килә торган оешма җитәкчесенә, имза салдыру өчен, административ хокук бозу турында беркетмәне тапшыруны тәэмин итә;

үтәү срогы: беркетмә төзелгәннән соң өч көн эчендә;

–оешма җитәкчесе имза салудан баш тартканда, административ хокук бозу турында беркетмәгә тиешенчә язып куя;

үтәү срогы: турыдан-туры беркетмәгә имза салудан баш тартылганнан соң;

– үзе килеп алмаган очракта, 3 көн эчендә оешма җитәкчесенә административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсен җибәрүне (почта аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) яки факсимиль элемтә аша яисә электрон почта аша) тәэмин итә;

үтәү срогы: күп дигәндә өч эш көне эчендә;

– административ хокук бозу турында эшне карап тикшерү өчен гомуми юрисдикциядәге судка административ хокук бозу турында беркетмәне почта

аша заказлы хат белән (тапшыру турында уведомление белән) җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: күп дигәндә өч тәүлек эчендә;

– үзенә карата административ хокук бозу турында эш кузгатылып килә торган оешма җитәкчесеннән административ хокук бозу турында беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртүләр алынганда, аларны билгеләнгән тәртиптә административ хокук бозу турында эшне тикшерергә тиешле гомуми юрисдикциядәге судка җибәрүне тәэмин итә;

үтәү срогы: күп дигәндә бер эш көне эчендә;

– административ хокук бозу турында беркетмә күчермәсен тикшерү материалларына теркәп куя;

үтәү срогы: административ хокук бозу турында беркетмә (беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар яки искәртүләр) гомуми юрисдикциядәге судка җибәрелгәннән соң бер эш көне эчендә.

5.7.4. Оешма планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча бирелгән күрсәтмәне ике ай эчендә үтәмәгән очракта, җаваплы эш башкаручы, күрсәтмәне үтәү срогы чыкканнан соң 5 эш көне эчендә прокуратура органнарына, гаепле затларны РФ КоАП 19.5 статьясындагы 1 өлеше нигезендә административ җаваплылыкка тарту һәм башка прокурор җавабы чаралары күрү турында тәкъдим белән, мөрәҗәгать җибәрә.

үтәү срогы: күрсәтмәне үтәү срогы чыкканнан соң 5 эш көне эчендә.

5.7.5. Җаваплы эш башкаручы оешма җитәкчесеннән Министрлыкка түбәндәгеләр турында мәгълүмат алынуына контрольлек итә:

тикшерүләр барышында ачыкланган халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозуларны юкка чыгару;

халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуны юкка чыгару турында күрсәтмәне үтәү.

5.7.6. Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты Министрлыкка оешма җитәкчесеннән гомуми юрисдикциядәге суд тарафыннан билгеләнгән карарны үтәү турында мәгълүматның керүенә контрольлек итә.

5.7.7. Тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары булганда тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү буенча карар кабул итү критерие булып тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактларының урын алуы тора.

5.7.8. “Тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары булганда тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү” административ процедурасының нәтиҗәсе булып үтәлеше мәҗбүри булган түбәндәгеләр тора:

– халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуларны юка чыгару турында күрсәтмә;

– административ хокук бозу турында беркетмә.

5.7.9. “Тикшерү актында халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозу фактлары булганда тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча чаралар күрү” административ процедурасын үтәү нәтиҗәсе халыкны эш белән тәэмин итү һәм инвалидларны эшкә алу өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендәге закон бозуларны юка чыгару турында күрсәтмәдә һәм /яки административ хокук бозу турында беркетмәдә теркәлә.

## 6. Дәүләт вазыйфасын үтәүгә контрольлек итү тәртибе һәм формалары

6.1. Министрлык тикшерүләр үткәрү барышында вазыйфаи затларның хезмәт бурычларын үтәвенә контрольлек итә, вазыйфаи затларның үз вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәве очраклары учетын алып бара, хезмәт урынында тиешле тикшерүләр үткәрә һәм мондый затларга карата Россия Федерациясе законы нигезендә чаралар күрә.

6.2. Бу Административ регламентның үтәлүенә контрольлек итүне министр хәл кыла.

6.3. Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан бу Административ регламент нигезендә дәүләт күзәтчелеге һәм контрольлеге срокларын, аларны үтәү буенча гамәлләрнең эзлеклелеген үтәүгә, вазыйфаи затлар тарафыннан карарлар кабул итүгә агымдагы контрольлекне министр урынбасары, Бүлекләр начальниклары һәм Министрлыкның вәкаләтле хезмәткәрләре хәл итә.

6.4. Дәүләт функциясен үтәүгә агымдагы контрольлекне хәл итүгә вәкаләтле Министрлык хезмәткәрләре исемлеге, әлеге контрольлекне хәл итү тәртибе һәм вакыт аралыклары Министрлык актлары нигезендә билгеләнә. Агымдагы контрольлекне хәл итүгә Министрлык хезмәткәрләренең вәкаләтләре Министрлыкның структур подразделениеләре турында нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазыйфаи инструкцияләрендә билгеләнә.

6.5. Агымдагы контрольлек бу Административ регламент нигезләмәләренең һәм дәүләт функциясен үтәүгә карата таләпләрне билгеләүче башка норматив–хокукый актлар нигезләмәләренең үтәлүенә тикшерүләр үткәрү юлы белән хәл ителә. Тикшерүләр үткәрүнең тулылыгына һәм сыйфатына агымдагы контрольлек даими нигездә хәл ителә һәм мөрәҗәгать итүчеләр хокукларын бозу очракларын тикшерүне, ачыклауны һәм билгеләүне, тиешле бозуларны юкка чыгару турында карарлар кабул итүне үз эченә ала.

6.6. Дәүләт функциясен үтәүгә контрольлек итү планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрүне үз эченә ала.

Дәүләт функциясен үтәүнең тулылыгына һәм сыйфатына планлы тикшерүләр Министрлыкның агымдагы елга еллык эш планы нигезендә үткәрелә. Планлы тикшерүләр әлеге планга, Бүлекләр начальниклары белән килешенеп, күзәтчелек һәм контрольлек мәсьәләләре буенча министр урынбасары тарафыннан кертелә.

Планнан тыш тикшерүләр элек ачыкланган бозуларның юкка чыгарылуын тикшерүгә бәйле рәвештә, шулай ук Министрлыкның вазыйфаи затларының вазыйфаи бурычларын үтәүдәге гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаятьләр нигезендә үткәрелә.

6.7. Министрлыкның дәүләт функциясен үтәүгә җаваплы вазыйфаи затлары дәүләт функциясен үтәүләре барышында кабул иткән (тормышка ашырган) карарлары, кылган гамәлләре (гамәл кылмау) өчен җавап бирә.

Министрлыкның вазыйфаи затларының җаваплылыгы, Россия Федерациясе законы таләпләре нигезендә, үзләренең вазыйфаи инструкцияләрендә билгеләнә.

Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында Министрлык мондый чаралар күрелгәннән соң ун көн эчендә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре санга сугылмаган оешмага язмача хәбәр итәргә тиеш.

6.8. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан дәүләт функциясен үтәүгә контрольлек телефон, язмача мөрәҗәгатьләр, электрон почта аша, Министрлык сайтында һәм Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша мәгълүмат алу юлы белән хәл ителергә мөмкин.

6.9. Бу Административ регламентны үтәү тәртибенә һәм контрольлек формаларына карата таләпләрне, шул исәптән гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан, таләпләрне ачыклаучы төп нигезләмәләр федераль законнар, шулай ук Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

## 7. Дәүләт функциясен үтәүче органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

7.1. Юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, кызыксынулы башка затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тикшерү үткәргәндә, билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алганда аларның хокукларын бозуга китергән Министрлык, аның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш), Россия Федерациясе законында билгеләнгән тәртиптә, шикаять белдерүгә хокуклы.

Мөрәҗәгать итүче кәгазьдә язмача шикаять белән мөрәҗәгать итүгә яки электрон рәвештә почта аша яисә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлык сайты (http://mtsz.tatarstan.ru) аша яки Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү

порталы (http://uslugi.tatar.ru) аша шикаять җибәрүгә, шулай ук Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә шикаять тапшыруга хокуклы.

7.2. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып Министрлыкның вазыйфаи затларының дәүләт функциясен үтәү барышында кабул иткән карарлары яки кылган гамәлләре (гамәл кылмау) тора.

7.3. Шикаятьне карап тикшерүне туктатып торуга яки аны карап тикшерүдән баш тартуга нигезләр күздә тотылмаган. Министрлыкка яки аның вазыйфаи затына алынган шикаять, компетенцияләренә бәйле рәвештә, мәҗбүри тәстә карап тикшерелергә тиеш.

7.4. Түбәндәге очракларда шикаятькә җавап бирелми:

– шикаятьтә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (юридик зат атамасы) яки җавап җибәрү өчен почта адресы (электрон адрес) күрсәтелмәсә;

– шикаятьтә вазыйфаи затка, шулай ук аның гаиләсе әгъзаларына карата әдәпсез яки кимсетү сүзләре, тормышына, сәламәтлегенә, милкенә янау урын алса (Министрлыкның вазыйфаи заты шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә үз хокукыннан явыз ниятә файдаланырга ярамавы турында хәбәр итүгә хокуклы);

– почеркы начар булу сәбәпле, текстны укып булмаганда, бу хакта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә шикаять теркәлгәннән соң җиде көн эчендә хәбәр ителә, аның фамилиясен һәм почта адресын (электрон адрес) укып булганда;

– мөрәҗәгать итүченең шикаятендә элек җибәрелгән шикаятьләренә бәйле рәвештә берничә тапкыр язмача җаваплар бирелгән мәсьәлә урын алып, шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яки хәлләр күрсәтелмәсә (әлеге шикаять һәм элегрәк җибәрелгән шикаятьләр шул бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яки шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән очракта министр, вазыйфаи зат яки вәкаләтле зат чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм әлеге мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән хат язышуны туктату турында карар кабул итүгә хокуклы; шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хат язышуны туктату турында карар кабул ителү хакында җиткерелә).

Шикаятьтә әзерләнелә, кылына торган яки кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар урын алганда, шикаять тиешле компетенциядәге дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять, теркәлгәннән соң җиде көн эчендә, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире кайтарып бирелә.

Шикаятьтә куелган сорауга җавап бирү дәүләт сере яки федераль закон нигезендә саклана торган башка төрле сер булып торучы мәгълүматларны таратуга китерердәй очракта шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә, куйган соравына, әлеге мәгълүматларны таратуга юл куелмау сәбәпле, җавап биреп булмау турында хәбәр ителә.

Шикаятьтә куелган сорауларга җавап биреп булмау сәбәпләре алга таба юкка чыгарылган очракта, мөрәҗәгать итүче Министрлыкка яки аның вазыйфаи затына янә шикаять җибәрүгә хокуклы.

7.5. Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмау) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процедурасын башлауга нигез булып Министрлыкка мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиле) шәхсән үзеннән яки почта аша хат рәвешендә яисә "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталы" федераль дәүләт мәгълүмат системасы аша электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать (шикаять) алыну тора.

7.6. Мөрәҗәгать итүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле мәгълүмат һәм документлар алуга хокуклы. Мөрәҗәгать итүчеләр, мондый мәгълүмат һәм документлар алу өчен, Министрлыкка язмача яки электрон рәвештә тиешле запрос җибәрергә тиеш. Министрлыкның вазыйфаи затлары, запрос теркәлгәннән соң 30 көн эчендә, мөрәҗәгать итүче сораган мәгълүматларны һәм документларны тапшыруга бурычлы, Россия Федерациясе законында билгеләнгән мәгълүмат алуга чикләүләр булмаган очракта.

7.7. Министрлыкның вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять министрга җибәрелергә мөмкин. Министрлыкның һәм министрның гамәлләренә (гамәл кылмау) шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.8. Шикаятьләр, теркәлгәннән соң 30 көн эчендә, Министрлык тарафыннан карап тикшерелә.

7.9. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре булып тора:

– дәүләт күзәтчелеге һәм контрольлеге барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмау) һәм кабул ителгән (тормышка ашырылган) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндерү, тәгаенләп әйткәндә:

хезмәт урынында тикшерү барышында вазыйфаи зат (вазыйфаи затлар) тарафыннан үзенең хезмәт бурычларын тиешенчә үтәмәве ачыкланган очракта вазыйфаи затка (вазыйфаи затлар) карата Россия Федерациясе законы нигезендә чаралар күрү;

үзенең хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка Россия Федерациясе законын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында, мондый чаралар кабул ителгәннән соң ун көн эчендә, язмача рәвештә белдерү кәгазе җибәрү;

– дәүләт күзәтчелеге һәм контрольлеге барышында кылынган гамәлләргә (гамәл кылмау) һәм кабул ителгән (тормышка ашырылган) карарларга судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне канәгатьләндермичә калдыру, юридик затка мондый карарның сәбәбе турында язмача хәбәр итеп.

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
25 сентябрь, 2014 ел, №518 боерыгы
белән расланган Административ
регламентка №1 кушымта

(Үрнәк форма)

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны
эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы
хаты бланкында

КҮРСӘТМӘ №
ачыкланган бозуларны юкка чыгару турында

"__"_____20__ел ______________________________
(күрсәтмә бирү урыны: торак пункт атамасы)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(эш бирүченең вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме, тулы атамасы

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

"__"_____елдан "__"_____елга кадәрге чорда Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының вазыйфаи затлары

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Тарафыннан тикшерү үткәрелде

______________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(эш бирүчеләрнең билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу турында законны үтәүләрен, билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә урнаштыру өлкәсендә закон бозуларны ачыклау)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

(эш бирүченең тулы атамасы)

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

"Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында" 19.04.1991 ел, №1032-1 Россия Федерациясе Законы нигезендә һәм "__"_____20_ел, № тикшерү актына туры китереп, ачыкланган бурычларны юкка чыгару һәм түбәндәге таләпләрне үтәү бурычын үз өстемә алам:

| №п/п | Тикшерү актында теркәлгән бозуларны юкка чыгару турында таләпләр исемлеге |
|---|---|
| | |
| | |
| | |

_________________________ _____________________ _____________________

(күрсәтмә чыгарган затның вазыйфасы атамасы) (Ф.И.О.) (имзасы)

Күрсәтмәне үтәүгә алды:

______________________ _____________________ __________________

(вазыйфасы) (Ф.И.О.) (имзасы)

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү һәм
социаль яклау министрлыгының
25 сентябрь, 2014 ел, №518
боерыгы белән расланган
Административ регламентына №2
кушымта

# БИЛГЕЛӘНГӘН КВОТА ЧИКЛӘРЕНДӘ ИНВАЛИДЛАРНЫ ЭШКӘ АЛУГА КҮЗӘТЧЕЛЕК ҺӘМ КОНТРОЛЬЛЕК БУЕНЧА, ТИКШЕРҮЛӘР ҮТКӘРҮ, ҮТӘҮ ӨЧЕН МӘҖБҮРИ БУЛГАН КҮРСӘТМӘЛӘР БИРҮ ҺӘМ БЕРКЕТМӘЛӘР ТӨЗҮ ХОКУКЫ БЕЛӘН, ДӘҮЛӘТ ФУНКЦИЯСЕН ҮТӘҮНЕҢ

## БЛОК-СХЕМАСЫ

Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу буенча тикшерүләр үткәрү

↓

Күчмә һәм документар тикшерүләр үткәрү планын әзерләү һәм раслау

Билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алу буенча планнан тыш күчмә һәм планнан тыш документар тикшерүләр үткәрү планлы күчмә һәм планлы документлар тикшерүләр үткәрү

↓

Инвалидлар өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозу очраклары турында мәгълүмат алыну


Планлы күчмә тикшерү үткәрү турында боерыкны раслау
Планлы документар тикшерү үткәрү турында боерыкны раслау
Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында боерыкны раслау
Планнан тыш документлар тикшерү үткәрү турында боерыкны раслау
Оешмага планлы күчмә тикшерү үткәрү турында җиткерү
Оешмага планлы документар тикшерү үткәрү турында җиткерү
Оешмага планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында җиткерү
Оешмага планнан тыш документар тикшерү үткәрү турында җиткерү
Планлы документлар тикшерү үткәрү өчен оешманың кирәкле материалларны тапшыру зарурилыгы турында запрос (таләп) җибәрү
Планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен оешманың кирәкле материалларны тапшыру зарурилыгы турында запрос (таләп) җибәрү
1

1

↓

Тикшерү үткәрү

↓

Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле хезмәткәрләр оешма тарафыннан бу Административ регламентның 2 таблицасында бәян ителгән мәҗбүри таләпләр үтәлешен, шул исәптән:
оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә инвалидларны эшкә алу өчен билгеләнгән квота чикләрендә эш урыннары бирү (булдыру) турында мәгълүмат тапшыру (инвалидларны эшкә алу өчен оешма тарафыннан бирелгән (булдырылган) эш урыннары (шул исәптән махсус) санының инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон таләпләренә туры килүе);
оешма тарафыннан инвалидларны эшкә урнаштыру өчен билгеләнгән квотаны үтәү (билгеләнгән квота чикләрендә инвалидны эшкә алудан нигезсез баш тартуның булмавы);
оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә билгеләнгән квоталар кысаларында бушый торган, бирелгән яки булдырылган  эш урыннары турында мәгълүмат тапшыру;
оешма тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә инвалидларны эшкә алу өчен квотаны үтәү турында мәгълүмат тапшыру буенча мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен тикшерә

↓

Тикшерү актын төзү

↓ ↓

Бозулар ачыкланса

Бозулар ачыкланмаса

↓

Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты инвалидлар өчен эш урыннарын квоталау өлкәсендә закон бозулар урын алганда, шулай ук административ хокук бозу составы билгеләренә бәйле рәвештә:
Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.42 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә төзи;
Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.7 статьясында күздә тотылган административ хокук бозу турында беркетмә төзи.
Җаваплы эш башкаручы, ачыкланган бозуларны юкка чыгару срогын күрсәтеп, гамәлдәге законны бозуларны юкка чыгару турында үтәлеше мәҗбүри булган күрсәтмә тапшыра.

↓

Министрлыкка гамәлдәге законны бозуларны юкка чыгару турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокта аларны юкка чыгару турында мәгълүмат алынмаганда, Министрлыкның юридик бүлегенең вазыйфаи заты Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 19.5 статьясындагы 1 өлешендә күздә тотылган административ хокук бозу турында эш кузгата.